РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

БОЛЬШЕШИНАРСКИЙСЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большой Шинар, ул. Кооперативная, 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422054, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Шынар авылы, Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

14.09.2018 — №20-п

Олы Шыңар авыл Башкарма комитетының
2017 елның 15 мартында 4 нче номер белән расланган
“Олы Шыңар авыл Башкарма комитеты
тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү
өчен җир кишәрлеге бирү” муниципаль хезмәте күрсәтү
Административ регламентын раслау турында” карарына
үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 2018 елның 10 сентябрендәге 02-01-20-18 нче номерлы хаты нигезендә, Олы Шыңар авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Олы Шыңар авыл Башкарма комитетының 2017 елның 15 мартында 4 нче номер белән расланган “Олы Шыңар авыл Башкарма комитеты тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерүөчен җир кишәрлеге бирү” муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында” карарының 5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 8 һәм 9 пунктчалар белән тулыландырырга:

“8) дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирүнең срогы яки тәртибе бозылу;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктатып тору федераль законнар һәм аларга яраклаштырып кабул ителгән Рәсәй Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары, Рәсәй Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары һәм законнары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта, әгәр күпфункцияле үзәккә Федераль законның 16 нчы матдәсе, 1_3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәленә(гамәл кылмавына) һәм карарларына судка кадәр(судтан тыш) шикаять бирү мөмкин.”

Авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов